ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь, 2019 ел № 33/9

Шәһәр Советының 2016 елның 07 апрелендәге 7/6 санлы Карары белән расланган 2021 елга кадәр һәм 2030 елга кадәр чор өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш Стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2014 елның 28 июнендәге «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 172-ФЗ Федераль закон, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2016 елның 07 апрелендәге 7/6 санлы Карары белән расланган 2021 елга кадәр һәм 2030 елга кадәр чор өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш Стратегиясенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) «Норматив-хокукый базаны эшләү һәм корректировкалау хокукый дәрәҗәсе» бүлегендә «2030 елга кадәр Чаллы шәһәрен тотрыклы үстерү моделе» таблицасының 3 нче бүлегендә «Акыллы автобус» сүзләрен төшереп калдырырга.

2) 5 бүлектә:

- 5.3 бүлекчәсендә:

«Өстенлекле бурычлар» бүлегенең 1 пункты 5.3.1 пунктчасында «муниципаль булмаган» сүзләрен «шәхси» сүзенә алыштырырга;

Түбәндәге эчтәлектәге 5.3.5 пунктын өстәргә:

**«5.3.5. Яшьләр сәясәте - «Яшьләргә бар нәрсә дә бары тик үзләре катнашында!»**

Яр Чаллы шәһәренең демократик үзгәрешләр юлыннан алга бару темпы яшьләрнең иҗтимагый-сәяси тормышында тоткан позициясенә, аның иртәгесе көнгә һәм активлыгына бәйле.

Шәһәрнең уңышлы социаль-икътисадый үсеше яшьләрнең тормыш перспективаларын шәһәр белән бәйләвеннән һәм кирәкле ресурсларга һәм мөмкинлекләргә ия булудан билгеләнә.

Яшьләрнең заманча стандартлар нигезендә активлыгын тәэмин итү шәһәрдәи нновацион яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру шартларында гына мөмкин.

Дәүләт яшьләр сәясәте үзенчәлекләреннән чыгып, тармакара өлкә буларак, яшьләр проблемаларын: мәгариф, эшкә урнаштыру, ял оештыру, социаль-тискәре күренешләрне профилактикалау һәм башка мәсьәләләр буенча ведомстволар арасында координацияне ныгытырга кирәк.

**Максат:** яшьләргә социальләшү һәм актив рәвештә үз юлларын табарга булышу, яшьләрнең җәмгыятьтәге социаль-икътисадый хәлен яхшырту, яшьләр арасында социаль-тискәре күренешләрне киметү.

**Шәһәр яшьләр сәясәтенең конкурентлы өстенлекләре:**

– яшьләр сәясәте инфраструктурасы: 4 яшьләр үзәге, 26 яшүсмерләр-яшьләр клубы, 13 хоккей корты һәм 4 социаль учреждение үсә һәм максималь рәвештә кулланыла;

– яшүсмерләр-яшьләр клубларын һәм яшьләр үзәкләрен реновацияләү үткәрелә;

– Татарстан Республикасы җитәкчелеге ярдәме белән «Техношәһәр» уникаль күпфункцияле өстәмә белем бирү үзәген проектлау башланды, ул «КАМАЗ» ГАҖ резерв җирләрендә урнашачак;

– яшьләр арасында социаль-тискәре күренешләрне профилактикалауда ведомствоара хезмәттәшлек системасы төзелде;

– шәһәрнең яшьләр сәясәте учреждениеләрендә нәтиҗәле кадрлар составы бар;

– яшьләр иҗтимагый хәрәкәте үсә.

**Эчке мохитнең төп таләпләре (шәһәр проблемалары):**

– социализациягә, яшьләрне җәлеп итүнең түбән дәрәҗәсенә һәм аларның бердәм икътисадый, сәяси һәм социаль-мәдәни пространствога интеграцияләнүенә бәйле проблемалар булу;

– яшьләр арасында социаль-тискәре күренешләрнең югары дәрәҗәсе: тәмәке тарту, алкоголь һәм психоактив матдәләр куллану, хокукка каршы гамәлләр кылу, асоциаль төркемнәрдә катнашу, суицидаль тәртип;

– яшьләр сәясәте учреждениеләрендә яшьләр, хәвефле төркемдәге яшьләр белән индивидуаль юнәлештәге психологик-педагогик эш өчен өчен кызыклы яңа технологияләр һәм эш формаларын тиз һәм нәтиҗәле кертергә мөмкинлек бирүче актуаль матди-техник база булмау;

– яшьләр белән эшләүче белгечләрнең программаларына ярдәм итү һәм аларны үстерү өчен муниципаль грантлар булмау, шул сәбәпле, яшьләр сәясәте өлкәсенә яңа яшь кадрларны җәлеп итүдә эшчәнлеккә мотивациянең түбән дәрәҗәсе һәм кыенлыклар булу;

– яшьләр эшмәкәрлегенең җитәрлек дәрәҗәдә үсмәве;

– яшьләр арасында гаилә кыйммәтләренең өстенлеге кимү.

**Өстенлекле бурычлар:**

– барлык категория яшьләрнең муниципаль учреждениеләр хезмәтләреннән файдалануын тәэмин итү;

– яшүсмерләр һәм яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тотышын кисәтүгә, социаль-куркыныч хәлдәге балаларга һәм яшьләргә ярдәм итү юнәлешендә чаралар оештыру;

– балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең ялын оештыру;

– вакытлыча эшкә урнашуны оештыру;

– Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт яшьләр сәясәте активистларының кадрлар резервына теләктәшлек итү һәм аны үстерү;

– яшьләр арасында инновацияләрне һәм фәнни-техник иҗатны популярлаштыруга, яшьләрнең инновацион проектларны шәхси әзерләвенә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм уздыру;

– Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшьләр арасында эшмәкәрлекне үстерү (уен, тренинг һәм башка проектларны, белем бирү курсларын, 14-17 яшьлек яшүсмерләр һәм яшьләр арасында конкурсларны гамәлгә ашыру; яшьләрне эшмәкәрлеккә җәлеп итүгә юнәлдерелгән мәгълүмат кампаниясен уздыру);

– төрле социаль юнәлештәге яшьләр иҗтимагый хәрәкәтен (ирекле инициативалар, хокук саклау хәрәкәте, иҗади һәм мәдәни проектлар, эшмәкәрлек һәм бизнес, экологик төркемнәр һәм башкалар) яклау һәм үстерү;

– дәүләт тарафыннан аерым кайгыртуга мохтаҗ яшүсмерләр һәм яшьләргә яшәү урыны буенча учреждениеләрнең иң якын урында урнашу принцибы нигезендә социальләштерү өчен шартлар тудыру;

– яшүсмерләр һәм яшьләрне психологик ярдәм белән тәэмин итү;

– яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне гражданлык һәм патриотик тәрбияләүгә, яшьләр арасында толерантлык тәрбияләүгә, хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләрне формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру;

– Яшьләр үсеше өчен уңайлы мәгълүмат кырын формалаштыру, дәүләт структуралары, иҗтимагый берләшмәләр һәм яшьләр арасында үзара элемтә механизмнарын булдыру, шулай ук мәгълүмати инфраструктураны яшьләрне патриотик һәм гражданлык тәрбиясе мәнфәгатьләрендә куллануның нәтиҗәлелеген арттыру;

– яшь гаиләләргә гаилә мәдәнияте кыйммәтләрен формалаштыруга һәм уңышлы яшь гаилә образын формалаштыруга, яшь гаиләләргә һәрьяклап ярдәм итүгә, аерылышулар санын киметүгә юнәлтелгән

уңайлы шартлар тудыру;

– сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыру, яшьләрнең физик үсеше өчен шартлар тудыру, экологик культура формалаштыру, шулай ук яшьләрнең тормыш эшчәнлеге иминлеге культурасы дәрәҗәсен күтәрү.»;

– «Өстенлекле бурычлар» бүлегенең 5.4 бүлекчәсендәге 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Актив озын гомерлелеккә ярдәм итү максатларында өлкән яшьтәге кешеләргә социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын һәм мөмкинлеген арттыру.»;

3) 6 бүлектә:

–«Шәһәрнең икътисадый сәясәте бурычлары» бүлегенең беренче пунктчасын «цифрлы технлогияләр кертү белән» сүзләре белән тулыландырырга;

– 6.2 бүлекчәнең 6.2.1 пунктындагы 5 абзацны көчен югалткан дип танырга;

– 6.2.3 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Матди капиталны куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып төп средстволарга кертелгән капиталның рентабельлелеге тора. Шәһәрдә төп фондларны куллану, җитештерү куәтләре, аларның искерүе, шулай ук рентабельлелек күрсәткечләре җыелмый. Шәһәр икътисадының рентабельлеген табыш һәм зыян күрсәткечләре аша чагылдырырга мөмкин. Шәһәр предприятиеләре алган табыш суммасы, 2017 ел белән чагыштырганда, 3,8 процентка артты, зыян 4,3 процентка кимеде. Табыш сальдосы 1,2 тапкырга артты.»;

– 6.2.5 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Интеллектуаль милек бәяләүчеләрне әзерләү мәктәбен үстерергә кирәк, чөнки мондый белгечләрнең булмавы интеллектуаль милек залогына кредит ресурсларын алу мөмкинлекләрен киметә.»;

– 6.2.6 пунктының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сәнәгать һәм индустриаль паркларда 2019 елның 1 июленә буш җитештерү мәйданнары бар: «КИП «Мастер» - 1%; «ПП «Развитие» - 3,7%; «Җиһазлар базасы» - 14%, «Экотехнопарк» - 2%, «Уналтынчы регион» - 32,4%, IT-парк – 10%.»;

7 абзацның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сәнәгый җитештерүнең гомумшәһәр күләме һәм шәһәр бюджетына салым түләүләре тупланган сәнәгать зонасының автомобиль юлларын реконструкцияләү проблемасы бар.»;

– 6.3 бүлекчәсендә 16 рәсем астында «- Технология университеты» сүзләрен төшереп калдырырга;

– 6.5 бүлекчәсенең «Өстенлекле бурычлар» бүлеген түбәндәге эчтәлектәге 12 пункт белән тулыландырырга:

«12. Предприятиеләрне хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга һәм төп фондларны модернизацияләүгә стимуллаштыру.»;

– 6.6 бүлекчәсендә:

Беренче абзацта «эчке базарны киңәйтүнең төп факторы буларак» сүзләрен «инновацион үсеш һәм икътисадның тармак структурасын яхшырту факторларының берсе буларак» сүзләренә алытырырга;

«Өстенлекле бурычлар» бүлегендә 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Кече һәм урта предприятиеләрнең дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга, аерым төр юридик затлар тарафыннан товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуда катнашу мөмкинлеген арттыру.»;

– 6.7 бүлекчәсендә:

«Өстенлекле бурычлар» бүлегендә 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Яр Чаллы шәһәренең инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру буенча комплекслы программа эшләү.»;

«Түбәндәге карарлар тәкъдим ителде» бүлеген гамәлдән чыккан дип танырга;

4) бүлектә 7:

– 20 рәсемнән соң 7.1 бүлекчәсенең 7.1.2 пунктын түбәндегә эчтәлектәге 8 абзац белән тулыландырырга:

«–яшеллек фондын һәм территорияләрне саклау, үстерү шартларында торак төзелеше максатларында җирләрдән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү.»;

– 7.2 бүлекчәсендә:

6 абзацны көчен югалткан дип танырга;

21 рәсемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:




21 рәсем. Кама агломерациясен үзгәртеп коруның төп юнәлешләре һәм шәһәр проектлары белән үзара бәйләнеш;

«Чаралар» бүлегенең икенче абзацын гамәлдән чыккан дип танырга;

- 7.3 бүлекчәсендә

7.3.1 пунктта «Иҗтимагый киңлекләрне үстерү» рәсемен түбәндәге редакциядәге рәсем белән алыштырырга:




7.3.3 пунктында:

«Гамәлләр юнәлеше» бүлеген түбәндәге эчтәлектәге 7 абзац белән тулыландырырга:

«7. Интеллектуаль Транспорт Системаларын кертү: юл хәрәкәте, җәмәгать транспорты белән идарә итүнең автоматлаштырылган системаларын кертү.»;

«Чаралар» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**Чаралар:**

1. Тышкы элемтәләр, территориянең агломерация үсеше, шәһәр эче челтәренә йөкләнешләр, заманча таләпләрне (автомобиль юллары челтәрен, тимер юл транспортын, елга портын, җәяүлеләр зоналарын, велосипед юлларын һ.б. кертеп) исәпкә алып, шәһәрнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү Программасын эшләү һәм тормышка ашыру.
2. Шәһәр тирәсендә транзит магистральләрне проектлау һәм төзү.
3. Трамвай юлларын проектлау һәм төзү.
4. Шәхси оешмаларны газ-мотор ягулыгында эшләүче техникадан файдалануга стимуллаштыру.
5. Җәмәгать транспорты үсеше һәм нәтиҗәлелеген арттыру Программасын гамәлгә ашыру.
6. «Акыллы транспорт» системалары элементларын эшләү һәм гамәлгә кертү. Мобиль кушымталарга җәмәгать транспортының ориентлаштыру навигация системасын эшләү һәм интеграцияләү.

7. Түләүле машина кую урыннары  зоналарын кертеп, машина кую урыннарын чикләү зоналарын билгеләү.»;

«Эшләүгә тәкъдим ителгән проектлар» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Эшләүгә тәкъдим ителгән проектлар:**


1. һ.Такташ урамын тоташтырып һәм Чаллы елгасы аша яңа күпер төзеп, , Мәскәү проспектын дәвам итү проекты.

2. М7 федераль трассасының Орловка божрасы һәм Сарман тракты районында күп катлы чишелешләр проектлары.

3. «Төньяк-Көнчыгыш» торак районында 63, 74 торак комплекслар буйлап, 1 нче автомобиль юлын дәвам итеп,  яңа магистраль төзелеше.

4. «Акыллы транспорт» флагман проекты;


25  рәсемне  түбәндәге редакциядә сурәтләргә:




.

25 рәсем.  Яр Чаллы шәһәренең урам-юл челтәрен үстерү


26-28 рәсемнәр өстәргә:




26 рәсем. Йөк транспорты транзиты өчен әйләнеп узучы трассаларны үстерү




27 рәсем. Даими пассажирлар йөртү автобус маршрутларының перспектив челтәре




28 рәсем. Трамвай маршрутларының перспектив челтәре;

28 рәсемнән соң, түбәндәге эчтәлектә бәян итеп, «АКЫЛЛЫ ТРАСПОРТ» флагман проекты» бүлеген өстәргә:

**«АКЫЛЛЫ ТРАСПОРТ» флагман проекты»**

Яр Чаллы үзенчәлекләрен исәпкә алып, транспорт агымнары белән идарә итүне оптимальләштерү һәм пассажирлар транспортын автоматлаштыру максатларында шәһәр һәм шәһәр яны пассажир транспорты белән идарә итүнең ярдәм мәгълүмат системасын булдыру тәкъдим ителә. Интеллектуаль мәгълүмат системасы:

1) юл йөрү документларын куллануны исәпкә алуны һәм юл йөрү өчен түләүне контрольдә тоту;

2) юл йөрү өчен түләүнең инновацион алымнарын, шул исәптән, кондукторсыз алымнарын кертү;

3) сезонлы үзенчәлекләрне исәпкә алып, пассажирлар агымын анализлау һәм фаразлау;

4) юл хәлен исәпкә алып, җәмәгать транспорты расписаниесенә оператив үзгәрешләр кертү;

5) йөкләнешне исәпкә алып, аерым маршрутларга, җәмәгать транспорты төрләренә һәм урам-юл челтәре тыгызлыгына карап, пассажирлар агымын яңадан бүлү;

6) диспетчерлык идарәсен, пассажирлар йөртүне планлаштыруны автоматлаштыру;

7) пассажирлар йөртүне оештыруга контрактлар әзерләү, үтәүне тикшереп тору һәм документлар белән бәйле процессларны автоматлаштыру;

8) гамәлдәге пассажирлар агымыннан чыгып, маршрутларга транспорт чаралары төрләрен оптималь сайлау, автомобиль паркын ремонтлауны һәм яңартуны планлаштыру;

9) транспорт чараларының торышын тикшереп тору мөмкинлеген бирә.»;

26 нчы рәсемне 29 нчы рәсем дип санарга;

- 7.4 бүлекчәсенең «Норматив-хокукый базаны эшләү һәм төзәтү хокукый дәрәҗәсе» бүлегендәге «Яр Чаллы шәһәренең тотрыклы территориаль-пространстволы үсеше моделен гамәлгә ашыру этаплары» таблицасында «акыллы автобус» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев